**Казан шәһәре Думасының**
**2025 елның 12 августындагы 10-40 номерлы карары**

**Казан шәһәре Думасының аерым карарларын**
**гамәлдән чыккан дип тану турында**

Муниципаль хокукый базаны гамәлдәге законнардагы үзгәрешләр нигезендә тәртипкә китерү максатыннан Казан шәһәре Думасы **карар бирде**:

1. Түбәндәгеләрне гамәлдән чыккан дип танырга:

1.1. Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Вәкиллекле органының 2005 елның 24 декабрендәге 16-5 номерлы «Муниципаль заказ турындагы нигезләмә хакында»гы карары;

1.2. Казан шәһәре Думасының 2008 елның 25 декабрендәге «Казан шәһәре Думасының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында»гы карарының 1 пункты;

1.3. Казан шәһәре Думасының 2006 елның 20 апрелендәге 14-8 номерлы «Гражданнарның җирле үзидарә органнарына юлланган мөрәҗәгатьләрен карап тикшерү тәртибен һәм срокларын раслау турында»гы карары;

1.4. Казан шәһәре Думасының 2008 елның 16 октябрендәге 17-34 номерлы «Казан шәһәре Думасының 14-8 номерлы “Гражданнарның җирле үзидарә органнарына юлланган мөрәҗәгатьләрен карап тикшерү тәртибен һәм срокларын раслау турында”гы карарына үзгәрешләр кертү хакында»гы карары;

1.5. Казан шәһәре Думасының 2011 елның 27 апрелендәге 7-5 номерлы «Казан шәһәре Думасының “Гражданнарның җирле үзидарә органнарына юлланган мөрәҗәгатьләрен карап тикшерү тәртибен һәм срокларын раслау турында”гы карарына үзгәрешләр кертү хакында»гы карары;

1.6. Казан шәһәре Думасының 2019 елның 20 июнендәге 25-34 номерлы «Казан шәһәре Думасының “Гражданнарның җирле үзидарә органнарына юлланган мөрәҗәгатьләрен карап тикшерү тәртибен һәм срокларын раслау турында”гы карарына үзгәрешләр кертү хакында»гы карары;

1.7. Казан шәһәре Думасының 2006 елның 8 июнендәге 12-9 номерлы «Казанның стратегик үсеш Генераль советы һәм аның Башкарма комитеты составлары турында»гы карары;

1.8. Казан шәһәре Думасының 2007 елның 17 маендагы 14-17 номерлы «Балаларга өстәмә белем бирү учреждениеләрендә түләүле хезмәт күрсәтүләр турында»гы карары;

1.9. Казан шәһәре Думасының 2008 елның 18 декабрендәге 6-37 номерлы «Муниципаль мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләрендә балаларны тәрбияләгән өчен ата-аналардан алына торган түләү турында»гы карары;

1.10. Казан шәһәр Думасының 2006 елның 17 февралендәге 3-6 номерлы «Гражданнарның хокукый акт булдыру инициативасын гамәлгә ашыру тәртибе турында»гы карары.

2. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырып чыгарырга.

**Шәһәр Мэры** **И.Р.Метшин**